**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзү турында» 2017 елның 26 маендагы ПУ-441 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 22 декабрендәге ПУ-1153 номерлы һәм 2018 елның 19 февралендәге ПУ-177 номерлы һәм 2018 елның 6 июнендәге ПУ-406 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан Т.П. Водопьяновны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына Фәттахов Дамир Илдус улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын кертергә;

в) оештыру комитеты әгъзасы В.А. Леоновның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы спорт министры».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 21 сентябрь
№ ПУ-678